**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5289**
**14.10.2020**

Муниципаль белем бирү оешмаларында
укучы инвалид балаларга ярдәм күрсәтү
чаралары турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2019 елның 6 декабрендәге 34/5 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль белем бирү оешмаларында укучы инвалид балалар өчен түләүсез кайнар ризык белән тукلануны 2020 елның 19 октябреннән билгеләргә:

1) 1-4 сыйныфларда укучылар өчен – икенче түләүсез кайнар ризык белән туклану;

2) 5-11 сыйныфларда укучылар өчен – ике тапкыр кайнар ризык белән туклану.

2. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә тәэмин итәргә:

1) Башкарма комитет һәм муниципаль белем бирү оешмалары арасында башка максатлар өчен субсидия бирүгә килешүләр төзүне;

2) муниципаль белем бирү оешмалары тарафыннан кайнар ризык белән тукландыруны оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүне сатып алуларны гамәлгә ашыруны.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында каралган чыгымнарны финанслауны 2020 елга шәһәр бюджетының «Гаиләне һәм балачакны саклау» 10.04 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 1 720,028 мең сум (бер миллион җиде йөз егерме мең егерме сигез) сум күләмендә, кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.Г. Хамаевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 14 октябрендәге
5289 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль белем бирү оешмаларында укучы инвалид
балаларның туклануын оештыру чыгымнары
сметасы

| Сыйныф | Балаларның гомуми саны | Туклануның уртача көнлек бәясе (сум) | Гомуми көннәр саны | Барлыгы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1-4 | 209 | 38,15 | 53 | 422, 588 |
| 5-11 | 272 | 90 | 53 | 1 297, 440 |
| барлыгы: | | | | 1 720, 028 |

Барлыгы: 1 720,028 мең сум (бер миллион җиде йөз егерме мең егерме сигез) сум.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева